| ГЛАВА<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.09.2009** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 221** |

Спортта югары нәтиҗәләргә ирешкән Зеленодольск муниципаль районы спортчыларына һәм тренерларына грант ярдәме күрсәтү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

ТР Зеленодольск муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы «Укуда һәм спортта югары нәтиҗәләргә ирешкән укучыларга, укытучыларга, спортчыларга һәм тренерларга грант ярдәме күрсәтү турында» 384нче карары нигезендә матди кызыксындыру һәм Зеленодольск муниципаль районы спортчыларына һәм тренерларына спорт нәтиҗәләрен күтәрүгә мотивация тудыру максатыннан

**Карар бирәм:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2014 елның 3 июнендәге 02-101 номерлы карары белән расланган «Спортта югары нәтиҗәләргә ирешкән Зеленодольск муниципаль районы спортчыларына һәм тренерларына грант ярдәме турында»гы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 3.1нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: "Грант алуга кандидатураларны тәкъдим итү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе тәкъдиме буенча гамәлгә ашырыла».

1.2 Нигезләмәнең 3.2нче пунктында «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт советында» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт буенча идарәдә Зеленодольск муниципаль районы спорт учреждениеләре җитәкчеләре" сүзләренә алмаштырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына, Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында, спортта югары нәтиҗәләргә ирешкән Зеленодольск муниципаль районы спортчыларына һәм тренерларына грант ярдәме күрсәтү өчен, финанс ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

3. Җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге җитәкчесе Д.С. Анисимовка әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе җитәкчесе Р. Р. Бариевка йөкләргә.

**А.В.Тыгин**